Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

9 февраль 2021 ел №28

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Башкарма комитетның 2020 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында отчеты

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителгән отчетны карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Совет КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Башкарма комитетның 2020 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында отчетын игътибарга алырга.

2. Башкарма комитетка 2021 елга беренче чиратта түбәндәге бурычларны билгеләргә:

- милли проектларны, федераль, республика һәм муниципаль программаларны, Әлмәт муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруны тәэмин итү;
- юл-урам челтәрен комплекслы модернизацияләү, җәмәгать урыннарын һәм квартал эчендәге территорияләрне төзекләндерү чараларын үткәрү;
- районның су ресурсларын чистартуга юнәлдерелгән экологик чараларны гамәлгә ашыру;
- муниципаль маршрут буенча пассажирлар ташуның сыйфатын арттыру;
- торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү бурычларын киметүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләү;
- муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру; сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәләрендә хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы;
- халыкны эш белән тәэмин итү һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны гамәлгә ашыруда кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү.

3. Район Башкарма комитетына хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар, социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов